КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 1 июнь г.Казань № 458

2019 елгы Red Bull Air Race авиаузышлар дөнья чемпионаты этабын һәм TIMERMAN триатлон буенча ярышлар үткәргәндә Татарстан Республикасы территориясендә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 нче пункты нигезендә, 2019 елгы Red Bull Air Race авиаузышлар дөнья чемпионаты этабын һәм TIMERMAN триатлон буенча ярышлар үткәргәндә кешеләр гомере иминлеген тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Казансу елгасында Миллениум күпереннән алып Кремль дамбасына кадәр (зона пилотирования этапа чемпионата мира по авиагонкам Red Bull Air Race 2019 года) кечкенә суднолар, шулай ук җилкәнле, йөреп кайту, спорт өчен каралган суднолар, шул исәптән гидроцикллар, байдаркалар, ишкәкле көймәләр куллануны түбәндәге вакытларда тыярга:

2019 елның 12 июнендә 07.30 сәгатьтән 19.00 сәгатькә кадәр;

2019 елның 13 июнендә 08.30 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

2019 елның 14 июнендә 08.30 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр;

2019 елның 15 июнендә 09.30 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр;

2019 елның 16 июнендә 11.00 сәгатьтән 17.30 сәгатькә кадәр.

2. 2019 елның 6 июлендә 09 сәгать 00 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр SVIYAGA SWIM – 2019 триатлон буенча ярышлар үткәрү вакытында Свияжск утравы чикләрендәге Зөя елгасы һәм Идел елгасы участогында азсыешлы

судноларны, җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне дә кертеп) яр буеннан 600 метр ераклыкта файдалануны тыярга.

3. Триатлон буенча Европа чемпионаты вакытында Миллениум күпереннән Кремль дамбасына кадәр Казансу елгасында түбәндәге көннәрдә азсыешлы судноларны, җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрен дә кертеп) файдалануны тыярга:

2019 елның 27 июлендә 08 сәгать 00 минуттан 18 сәгать 00 минутка кадәр;

2019 елның 28 июлендә 08 сәгать 00 минуттан 18 сәгать 00 минутка кадәр.

4. 2019 елның 31 августында 05 сәгать 30 минуттан 17 сәгать 00 минутка кадәр TIMERMAN FULL – 2019 триатлон буенча ярышлар үткәрү вакытында Свияжск утравы чикләрендәге Зөя елгасы һәм Идел елгасы участогында азсыешлы судноларны, җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне дә кертеп) яр буеннан 600 метр ераклыкта файдалануны тыярга.

5. Бу карарның 1 – 4 нче пунктларында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю 2019 елгы Red Bull Air Race авиаузышлар буенча дөнья чемпионаты этабы ярышларын һәм  триатлон буенча ярышларын әзерләү һәм үткәрү өчен җәлеп ителгән судноларга кагылмый дип билгеләргә.

6. Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карарның 1 – 4 нче пунктлары белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында, Идел, Зөя, Казансу елгалары акваторияләрендә көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында (шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша) мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

7. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә бу карарның 1 – 4 нче пунктлары белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында, Идел, Зөя, Казансу елгалары акваторияләрендә көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин